
# Дидактик уен

# Баласын тап

**3-4 яшь**




**Дидактик уен.**

**«Баласын тап»**

**Максат**. Йорт хайваннары һәм кыргый хайваннарның балалары турында белемнәрен ныгыту; рәсемдәге хайван балаларын зур хайваннар белән чагыштыру күнекмәләре бирү; авазларның дөрес әйтелешен кабатлау.

**Җиһазлар.** Йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар төшерелгән карточкалар.

**Уен барышы.** Бу уенда 5-6 бала катнаша ала. Уенчыларга дүрт рәсем төшерелгән зур карточкалар өләшелә.Анда йорт һәм кыргый хайваннар төшерелгән. Кечкенә карточкаларда хайваннарның балалары төшерелгән. Уенчылар шул кечкенә карточкалардан балаларын табарга тиешләр.

